**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Кирельский авыл җирлеге советы**
**Карары**

**2018 елның 20 сентябре** **№ 83**

**Җирле референдум үткәрү**
**инициативасы турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

“Сез 2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) һәм түбәндә аталган эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

**- Җирле әһәмияттәге автомобиль юллары белән бәйле юл эшчәнлеге;**
**- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру;**
**- Күмү урыннарын карап тоту.**

**Әйе** **Юк”**

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

Кирельский авылы, Гагарин урамы, 1 йорт (администрация  бинасы);

Кирельский авылы, Гагарин урамы, 14 йорт (“Раифа” кибете бинасы):

Кирельский авылы, Түбән   урамы, 6 йорт (китапханә бинасы);

Ишем авылы, Үзәк урам, 10 йорт (авыл клубы бинасы),

Мордва Каратай авылы, Үзәк урам, 7 йорт (КФҮ бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм “Интернет” челтәренең мәгълүмати-телекоммуникация рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башлыгы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы рәисе** **Ф.Я.Зиннәтуллин**